**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 01.08.2023** **№ 1004**

**РФ Кораллы Көчләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узучы өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашырган Биектау муниципаль районы мәгариф оешмаларында карап торган һәм тәрбияләгән өчен түләүдән азат итү турында**

Россия Федерациясе Президентының 2023 елның 14 февралендәге ПР-309 номерлы йөкләмәсе, Россия Федерациясе Оборона министрының 2022 елның 28 ноябрендәге йөкләмәсе, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 2022 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү буенча Штаб утырышының 2022 елның 6 октябрендәге 1 номерлы беркетмәсен Кушымта нигезендә расларга.

2. Биектау муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашырган мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән РФ Кораллы Көчләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узучы өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләрен азат итәргә.

3. «Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнә:

3.1. Мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган затларның гаиләләренә социаль ярдәм буенча штаб утырышы беркетмәсенең 1 нче пунктында күрсәтелгән ташламаны хәрби комиссариатның белем бирү оешмасында тәрбияләнүченең РФ Кораллы Көчләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узучы ата-анасын (законлы вәкилен) өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакыру турындагы белешмәсе нигезендә бирергә;

3.2. Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узучы өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны кире кайтарган очракта ташламаларның гамәлдә булуын туктатуны контрольдә тоту максатында хәрби комиссариат белән үзара хезмәттәшлекне алдан күрергә.

4. «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы (финанс органы)» МКУнә Биектау муниципаль районы мәгариф оешмаларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узучы өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләре тәрбияләнүчеләрен карап тотуны финанслауны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә, граждан тарафыннан өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәт узу, РФ Кораллы Көчләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узу вакытына кагыла дип билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 11 октябрендәге 974 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта

«Расланды»
Биектау муниципального районы
башкарма комитетының
2023 елның 01.08. 1004нче
номерлы карары белән

Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү буенча штаб утырышының 2022 елның 6 октябрендәге 1 номерлы беркетмәсе:

Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү максатларында:

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә хәрби хезмәткә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган хәрби хезмәткәрләр (алга таба - хәрби хезмәткәрләр) гаиләләренә социаль ярдәмнең түбәндәге өстәмә чаралары күрсәтелә:

**1. Балалар өчен:**

- муниципаль балалар бакчаларына йөрү өчен түләүдән азат итү;
- 1-11 сыйныфларда укучыларга бушлай кайнар ризык белән тукландыру;
- 1 дән 6 сыйныфка кадәр укучыларның озайтылган көн төркемнәренә беренче чиратта кабул итүне, шулай ук аның өчен түләүдән азат итү;
- мәктәпләрдә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендә түгәрәкләрдә һәм өстәмә белем бирү секцияләрендә дәресләр өчен, спорт корылмаларына (бассейн, боз сарае, фитнес залы) йөрү өчен түләүдән азат итү

**2. Өлкән яшьтәге туганнар, инвалидлар һәм инвалид балалар өчен:**

- инвалид балалар тәрбияләүче мохтаҗ гаиләләргә, өлкән яшьтәге гражданнарга, I һәм II төркем инвалидларына, гаиләнең составына бәйсез һәм керемнәре дәрәҗәсен исәпкә алмыйча, өйдә социаль хезмәт күрсәтү;
- гаилә составына бәйсез рәвештә, ветераннар йортына һәм социаль хезмәт күрсәтүнең башка стационар учреждениеләренә беренче чиратта җибәрү.

**3. Гаиләнең барлык әгъзаларына:**

- психологик ярдәм күрсәтү;
- гаилә алырга хокуклы социаль һәм башка түләүләрне, социаль ярдәм чараларын рәсмиләштерүдә ярдәм;
- юридик мәсьәләләр буенча консультацияләү.

**4.** 8843-65-747-89 телефоны буенча 8.00 дән 17.00 гә кадәр (Дүшәмбе-җомга) хәрби хезмәткә мобилизация буенча чакырылган затларның гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү **штабының кайнар линиясе эше оештырылды**.